РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
СОВЕТ МЕШИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
422062, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.Лесхоз, ул. Кукморская, 2а
тел.(84362) 44-2-19

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
МИШӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
422062, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Лесхоз бистәсе, Кукмара урамы, 2а йорт
тел. (84362) 44-2-19

e-mail: Mesh.sab@tatar.ru

25.03.2019 № 9

КАРАР РЕШЕНИЕ

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлегенең 17 нче ноябрендә кабул ителгән 27 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлеге территориясендә физик затларның милкенә салым турында " гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 булеге, Россия Федерациясе Бюджет Кодексының 64 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлеге Советы

Карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлеге Советының 2014 нче елның 17 нче ноябрендә кабул ителгән 27 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлеге территориясендә физик затларның милкенә салым турында»гы карарына (Советның 2015 нче елның 6 нче августында кабул ителгән 24 нчы, 2015 нче елның 12 нче октябрендәге 7 нче, 2018 нче елның 3 нче августындә кабул ителгән 16 нчы карарлары, 2018 нче елның 21 нче ноябрендә кабул ителгән 30 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“ 3. Түбәндәге ташламаларне кертергә:

3.1. Ике фатирдан торган күпфатирлы бер катлы торак йорттагы фатирга милек хокукы булган физик затларга әлеге фатирның гомуми мәйданының кадастр бәясендәге салым ставкасының процент өлеше буларак билгеләнә торган суммага исәпләнгән салым суммасын киметү рәвешендә бирелә.

Әгәр фатир гомуми өлешле милектә булса, ташламалар суммасы өлешләп милектәге һәр кеше өчен аның бу фатирга милек хокукындагы өлешенә пропорциональ рәвештә исәпләнә.

Шул ук вакытта әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташламалар суммасы исәпләнгән салым суммасыннан артып китә алмый.

3.2. 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк балалары булган гражданнар-физик затлар милкенә салым түләүдән азат ителә.

Салым ташламасы салым салу объектларының чикләнмәгән санына карата бирелә.

Салым ташламасы салым салу объектларының теләсә нинди төренә карата бирелә.

Салым ташламаларына хокукы булган физик затлар салым органына салым ташламалары бирү турында гариза бирәләр, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документлар бирергә хокуклы.».

2. Әлеге карарның 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә йогынтысын җәелдерергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион "Интернет" челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы, авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/mesha адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Мишә
авыл җирлеге башлыгы А.Х.Гатиятуллин